КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2022 ел, 29 декабрь г.Казань № 1440

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2022 ел, 22 февраль, 151 нче карары белән расланган Дәүләт (муниципаль) учреждениеләре булмаган коммерцияле булмаган оешмаларга Татарстан Республикасында җирле үзидарәне төзүгә һәм үстерүгә юнәлдерелгән чараларны гамәлгә ашыручы коммерцияле булмаган оешмалар хезмәткәрләренең хезмәте өчен түләүгә бәйле чыгымнарны финанс белән тәэмин итү (каплау) максатларында Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр бирү тәртибенә үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының "Дәүләт (муниципаль) учреждениеләре булмаган коммерцияле булмаган оешмаларга Татарстан Республикасында җирле үзидарәне төзүгә һәм үстерүгә юнәлдерелгән чараларны гамәлгә ашыручы коммерцияле булмаган оешмалар хезмәткәрләренең хезмәте өчен түләүгә бәйле чыгымнарны финанс белән тәэмин итү (каплау) максатларында Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр бирү тәртибен раслау турында һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасында җирле үзидарәне формалаштыруга һәм үстерүгә булышлык күрсәтүгә юнәлдерелгән чараларны гамәлгә ашыручы коммерциягә карамаган оешмаларга Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр бирү тәртибен раслау турында» 2011 ел, 24 август, 706 нчы карары белән расланган Татарстан Республикасында җирле үзидарәне формалаштыруга һәм үстерүгә булышлык күрсәтүгә юнәлдерелгән чараларны гамәлгә ашыручы коммерциягә карамаган

оешмаларга Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр бирү тәртибенә үзгәреш кертү хакында» 2022 ел, 22 февраль, 151 нче карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2022 ел, 2 август, 746 нчы карары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган Дәүләт (муниципаль) учреждениеләре булмаган коммерцияле булмаган оешмаларга Татарстан Республикасында җирле үзидарәне төзүгә һәм үстерүгә юнәлдерелгән чараларны гамәлгә ашыручы коммерцияле булмаган оешмалар хезмәткәрләренең хезмәте өчен түләүгә бәйле чыгымнарны финанс белән тәэмин итү (каплау) максатларында Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр бирү тәртибенә (алга таба - Тәртип) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

2 пунктның өченче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Субсидия турында белешмә, тиешле финанс елына һәм план чорына Татарстан Республикасы бюджеты турында Татарстан Республикасы законы (тиешле финанс елына һәм план чорына Татарстан Республикасы бюджеты турында Татарстан Республикасы законына үзгәрешләр кертү хакында Татарстан Республикасы законы) кабул ителгән көннән соң килә торган 15 нче эш көненнән дә соңга калмыйча, «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге Россия Федерациясе бюджет системасының бердәм порталында (алга таба – Бердәм портал) «Бюджет» бүлегендә Россия Федерациясе Финанс министрлыгы тарафыннан билгеләнгән тәртиптә урнаштырыла.»;

6 пунктның өченче абзацында «30 календарь көннән иртәрәк» сүзләрен «бишенче календарь көннән иртәрәк» сүзләренә алмаштырырга;

14 пунктның җиденче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«субсидия бирү тәмамлана торган төгәл дата һәм нәтиҗәсенең ахыргы күрсәткече (йомгакларның конкрет микъдари тасвирнамәсе);».

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин